Р Е С П У Б Л И К А
Т А Т А Р С Т А Н

И С П О Л Н И Т Е Л Ь Н Ы Й
К О М И Т Е Т С А Б И Н С К О Г О
М У Н И Ц И П А Л Ь Н О Г О Р А Й О Н А

Т А Т А Р С Т А Н
Р Е С П У Б Л И К А С Ы

С А Б А М У Н И Ц И П А Л Ь
Р А Й О Н Ы Н Ң Б А Ш К А Р М А
К О М И Т Е Т Ы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
25.12.2023

КАРАР
№ 2014-п

Күпфатирлы йорт белән идарә итү
ысулын сайлау турында карар кабул
итмәгән торак урынлы милекчеләргә
торак урынны карап тоткан өчен түләү
күләмен үзгәртүнең чик индексын
билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 маддәсенең 4 пункты, Россия Төзелеш министрлыгының 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын раслау тәртибен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында»гы боерык нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 4,5 процент күләмендә билгеләргә.

2. “Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексын билгеләү турында” Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 06 мартындагы 248-п номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад бүлеге башлыгы М.М. Баһмановка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов